


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№ 8, апрель, 2025 ел*




**26 апрель – бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көне.** Моннан нәкъ 139 ел элек бу көнне Казан губернасы Казан өязе Кушлавыч авылында (хәзерге ТР Арча районы) указлы мулла Мөхәммәдгариф Мөхәммәтгалим улы белән Бибимәмдүдә Зиннәтулла кызы гаиләсендә булачак шагыйрь дөньяга килә. Казан артында туса да, тормышында якты хатирәләр калдырган, иҗатының чәчәк аткан һәм шөһрәт казанган еллары Казанда уза.

Шагыйрь үзе язганча, «ярты төш мисалендә үтеп киткән 7 сәнәлек вакыт эчендә» утыздан артык басмасы дөнья күрә, талантлы шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче, публицист, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче булып танылa. Тукайның халыкчан, үлемсез һәм бәяләп бетергесез зур иҗаты бүген дә горур яңгырый!

Г. Тукай туган көн республикада Туган тел көне буларак та билгеләп үтелә. Бу көнне Казанда аның һәйкәленә чәчәкләр салына, Шигърият бәйрәме уза, шигырьләр-җырлар яңгырый, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителә.

Бәйрәм белән Габдулла Тукай талантын сөючеләр! Бу көнне мәктәбебездә зур чара – Тукай шигырьләрен сәнгатьле укучылар бәйгесе узды. Һәр сыйныфтан катнашучылар бар иде. Алар бик матур итеп үзләре яттан өйрәнгән шигырьләрен сөйләделәр. Жюри аларның чыгышын бик игътибар белән тыңлады. Соңыннан нәтиҗә ясалды. Укучылар грамота һәм дипломнарга ия булдылар. Чарабыз Г.Тукайның “Туган тел” шигырен, гимнын җырлау белән тәмамланды. Г.Тукайның иҗатына мәхәббәт һәм кызыксыну хисләре, олы хөрмәт тәрбияләнде бу кичәдә.





**Быел язлар үзгә...**

Борын төртеп килгән үләннәр дә башка төстә.
Башкачарак ява яңгыры да,
Артык сызылып ата кебек таңнары да.
Мунчалардан чыккан төтеннәр дә үзгә.
Кояшы да быел сипкел чәчми әле йөзгә.
Һавасын да быел ак күмәчкә ягып ашап була,
Шаярышып, йолдызлар да төнлә айны куа.
Язның тәүге чәчкәсенә быел карлар ява,
Шул ак карлар булсын иде җанга дәва.
Үзгә быел язлар...
Үзгә...
Башка төстә...
Әйдә, син дә кушыл, үзгә язга үз төсеңне өстә...

**10 нчы сыйныф укучысы ,Баһавиев Әдел**

**Кадерле сандык.**

Безнең өйдә бик борынгы заманнардан кулланылган сандык бар. Ул сандык бабаемның әнисенеке. Элек ул сандыкта бик күп әйберләр тотканнар. Чиккән сөлгеләр, урындыкка куя торган көрпәләр, алкалар, мәрҗәннәр, чиккән мендәр тышлары, матур бизәкле күлмәкләр һ.б. кирәк-яраклар урын алган. Аларны көндәлектә кулланганнар.

Минем сандыктагы бер борынгы күлмәк турында әйтеп китәсем килә. Ул күлмәк – кием элементы гына түгел. Бизәкле элемент кына түгел, тарихта һәм буыннар хәтерендә яши торган мәдәни мирасның мөһим өлеше дә булып тора. Борынгы күлмәкләр югары бәяләнгән һәм мода сөючеләр арасында аерым урын алып тора. Һәр яңа әйбер онытылган иске әйбер икәнен һәрвакыт күреп торабыз. Шушы борынгы күлмәкләргә карап, бүгенге дизайнерлар да өр-яңа күлмәк эскизлары уйлап чыгаралар. Хәзер тегелүче бизәкле милли күлмәкләр безне татар халкының үткән тарихы белән тоташтыра.

**Садриева Айсинә, 6 нчы сыйныф укучысы**

## Без - бәхетле гаилә



Һәр гаиләнең үз кешеләре, гореф – гадәтләре, бәйрәмнәре бар. Безнең гаилә туган көннәрне билгеләп үтәргә ярата. 26 нчы апрель , Г.Тукай туган көнне минем дәү әнием: Фазлиева Рәшидә
Рәфкать кызы туган . Ул 1966 нчы елның 26 апрелендә Арча районы Югары Көек авылында дөньяга килгән. 1983 нче елның маенда Күлле Киме урта мәктәбен тәмамлый. Шул елларда Югары Көек авылында китапханәче булып эшкә урнаша.1985 нче елда Күәм авылы егете Илфарга (дәү әтием) кияүгә чыга, матур гына тормыш корып җибәрәләр.
Күәм авылына килгәч, почтальон хезмәтен башкара. Газета һәм журналалр тарата. Авыл халкы аның бик ярата , хөрмәт итә.
Хезмәт юлын 2000 нче елдан, Күәм урта мәктәбендә техник хезмәткәр булып дәвам итә. Күп еллар ул хезмәтен яратып, җиренә җиткереп, намус белән башкара.
Тормышта да дәү әнием бик булган. 1 ул, ике кыз үстерделәр. Дәү әтием белән игә иң куеп эшлиләр. Хәзерге вакытта балаларының үз гаиләләре бар. Дәү әнием һәм дәү әтиемнең 8 оныгы үсеп килә. Алар лаеклы ялда. Дәү әниемнең туган көнендә бар балалары да җыйналды. Бүләкләр һәм котлаулар кабул итте ул көнне дәү әнием. Шатланды да, елап та алды. Без аны бик яратабыз, аңа озын гомер, сәламәт тормыш, тигезлек телибез.
Дәү әтием һәм дәү әнием белән мин бик горурланам.

**Фазлиева Зилә, 7 нче сыйныф укучысы**

## Алиябез!



«Созвездие - Йолдызлык» фестивале - ачык республика яшьләр эстрада сәнгате телевизион фестивале буларак быел 25 тапкыр узды. 5 нче сыйныф укучысы Галявиева Алия инде алтынчы елын бу бәйгедә катнашты, ул ел саен матур уңышлы чыгыш ясый. Быел да катнашып Казан шәһәренең «Уникс» концерт залында Алия сәхнәдә конферансье буларак өченче дәрәҗә дипломга лаек булды, бүләкләнде. Тырыш, житез, кәләч Алия сәхнәдә озын шигырьләр сөйли, сәнгатьне ярата. Тырышлыгы һәм таланты бәяләнеп күп санлы димлом грамота һәм кыйммәтле бүләкләр дә алды. Сыйныфта ул тырыш укучы, барлык чараларда актив катнашучы. Сыйныфташларының сорауларына Алия теләп җавап бирде:
-Озын шигырьләрне ничек истә калдырасың?
-Хәтерне гел ятлап кабатлап, күнектереп торам.
-Конкурентларга карашың?
-Уңай, аларның да чыгышларын карыйм,өйрәнәм.
-Синең остазың кем?
-Финә Раисовна, ул барлык сәхнә серләренә төшендерде, гаиләм әнием, якыннарым да гел ярдәм итә. Мина аларга рәхмәтле.
- Күп эшкә чыгышларга бәйгеләргә катнашырга ничек өлгерәсең?
- Кечкенәдән сәхнәне үз иттем, миңа чыгыш ясау ошый.
- Кем котлаганы иң истә калды?
- Мине Татарстан Республикасы рәисе Миннеханов Рөстәм Нургалиевич та котлады
- Сина тагын нәрсәләр ошый?
-ТНВ да «Шаян ТВ» да эшләү ошый, туганнарым, дусларым белән аралашу ошый, китаплар да укыйм.
Истә калган чыгышларың кайсылары?
Алар күп инде: Пирамидада чыгыш ясау ошады, анда беренче урынга лаек булдым.
Иҗат сәнгатьтә уңышка ирешү өчен күп көч һәм тырышлык сорала. Иҗади уңышларың дәвамлы булсын Алия!

**Сыйныф җитәкчесе Ганиева Л.Ф**

## Кара савыты



Кара савытыңнан илгә
Аклык тамган, моң
тамган,
Синнән, Тукай, җир йөзендә
Татар дөньясы калган.

Петербург малайлары
Бүләк иткән бу савыт
Синең күңелнең серләрен
Уртаклашкан җай табып.

Шаһиты ул шигырьләрнен...
Әрнүләрнең, шатлыкның.
Шагыйрь йөрәгенә сыймас,
Шагыйранә аклыкның!

Кара савытына каләм
Түгел... йөрәкне манып...
Язгансың, янып сүнгәнче
Кара күмергә калып.

Кара савыты... маэмай да
Көтә энә хуҗасын...
Бронза түгел, җанлы бугай -
Килә кулым сузасым.

Һәм әйтәсем - безнең Тукай
Пакъләгән дөньябызда
Шагыйрь кебек тугры булыйк
Халкыбыз каршысына.

**Батталов Аяз, 4 нче сыйныф укучысы**



**Хәтерлим мин әле бүгенгедәй**

Мин 9 нчы сыйныфны тәмамлыйм. Шул сәбәпле уку елы дәверендә булган иң кызыклы һәм истә калган вакытларны искә алам. Минемчә, 9 ел бик күп вакыт иде, ләкин ул 9 ел тугыз минуттай булып үтеп китте. Иң башта мин җәй ахырында үземнең мәктәпкә баруымны көттем. Беренче көннән үк мәктәпкә килеп керүгә, мине иң беренче башлангыч укытучым Гатаулина Гөлназ апа каршы алды, шул вакытны мин үземнең булачак дуслар, классташлар белән таныштым. Ә аннары инде 4 ел сизелмичә үтеп тә китте. Без үзебезнең мәктәп тормышының югары баскычын башладык. 5 нче сыйныфка күчкәндә безне Гайнетдинова Алия апабыз хөрмәтләп, елмаеп каршы алды. Ул вакытта инде без - Алия апа белән таныш идек, ул бездә кызыклы инглиз телен алып барды. Шулай 9 минут кебек 9 ел үтеп тә киткән бит... Хәзер безне үзебезнең олы юл көтә. Без үзебезнең укытучыларга безнең өчен кызыклы дәресләр алып барып, безгә белем биргәннәре, кирәк вакытта якында булып, авырлыкларда булышканнары өчен бик зур рәхмәтлебез. Мин үземнең мәктәп вакытларын, укыткан укытучыларымны һәрвакыт елмаеп искә төшерәчәкмен!

**Минлебаев Руслан, 9 нчы сыйныф укучысы**

Мәктәп еллары-гомерлеккә истә кала торган вакыт. Алар бик тиз уза. Озакламый без тугызынчы сыйныфны тәмамлыйбыз. Бу вакыт эчендә бик күп белем, яңалыклар, вакыйгалар булды. Бергәләп без кыенлыклар аша үттек, шатлыклы мизгелләр кичердек. Экскурсияләргә, музей, театрга бардык. Рәхәтләнеп үзебез спектакльләр куйдык. Татар, инглиз телендәге театр уйнауларыбыз белән алдынгы урыннар,үрләр яуладык. Әгәр мәктәптә берәр чара була дисәләр , без аны сыйныф белән башкардык.

**Зиганшина Зәмирә, 9 нчы сыйныф укучысы**

Мәктәп еллары..... 9 ел сизелми дә узып бара,әйтерсен лә бу еллар уз эченә куп кыйссаларны сыйдырган. Купме еллар агышы ,шат елмаюлы укучылар авазы.... Рәхмәт сина , Куәм мәктәбе !!! Ин беренче тапкыр - 5 класска ныклы адымнар белән килеп керуем, хөрмәткә лаек укытучымнын , Алия Рөстәм кызынын шат елмаюы белән каршы алуы , куңелгә уелып калган ин дулкынландыргыч мизгел. Мизгел генә мени соң, ә хәтер сандыгына уелып калган һәм калачак..

**Нигмазянов Ильмас 9 нчы сыйныф укучысы**

Менә бер айдан безнең чыгарылыш кичәсе булачак. Минем бу уңайдан төрле хисләрем бар. Бер яктан, мин хәзер үк сагыначагымны аңлыйм. Мәктәп минем тормышымда бик мөһим этап. Нәкъ менә шунда мин бөтен нәрсәгә өйрәндем. Укырга, язарга…. Минем яраткан дәресләрем барлыкка килде. Мәктәптә мин бик күп дуслар таптым, дуслыгыбызны саклап кала алырбыз дип өметләнәм. Укытучыларга шушы вакыт эчендә мин бик ияләштем. Минем мәктәп белән бик күп яхшы истәлекләр бәйле.Бу гаять зур вакыт эчендә бик күп нәрсәләр булды. Шатлыклы һәм моңсу вакытлар, очрашулар һәм аерылышулар, җиңүләр һәм җиңелүләр. Мин мәктәп көннәрен һәрвакыт җылылык белән искә алачакмын.

**Халикова Азалия, 9 нчы сыйныф укучысы**

9 ел уку дәвамында бик күп кызыклы һәм җылы күңелдә калырлык вакыйгалар булды. Мин уку дәверендә яхшы дуслар таптым, киләчәктә кирәк була торган белемнәр алдым. Һәр көн үзенчәлекле һәм кабатланмас булды. Мин классташларыма, белем биргән укытучыларыбызга, Нурания Идерис кызына, Алсу Мисалим кызына, Хәмит Газим улына, Ләйсән Фәргать кызына, Гөлнара Зөлкарь кызына, Булат Абдулл улына, Гөлфия Зөфәр кызына, Рәйсә Равил кызына, Алия Габдул кызына һәм әлбәттә сыйныф җитәкчебезгә - мәктәп еллары дәвамында булышкан, бергә булган өчен бик зур рәхмәтемне белдерәм!

**Шигапов Фәнил, 9 нчы сыйныф укучысы**

Кадерле укытучылар! Сезгә чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм. Сезнең тырышлыгыгыз һәм кайгыртучанлыгыгыз өчен зур рәхмәт. Шушы мәктәпкә килү белән мин яңа дуслар таптым. Яңа һөнәрләргә өйрәндем. Сыйныф җитәкчем миңа йөрәк җылысын бирергә тырышты. Рәхмәт Сезгә Алия Рөстәм кызы. Сезнең һәр дәресегез, һәр киңәшегез минем өчен бик кыйммәтле. Аннары хезмәткә өйрәткән Фәрдия апага зур рәхмәт. Ул мине тегәргә, тәмле ризык пешерергә өйрәтте. Сезнең ярдәмегез һәм үзегезнең шәхси үрнәгегез безнең киләчәгебезне формалаштырды. Зур рәхмәт сезгә.

**Мирхазианова Азалия, 9 нчы сыйныф укучысы**

Һәр яңа көн безгә яңа үрләр, хис кичерешләр, белем һәм максат бирде. Шушы 9 ел эчендә мәктәп миңа бары уңай яктан гына тәэсир итте. Мине шәхес итеп тәрбияләде.Тугыз ел эчендә без спорт өлкәсендә, олимпиадаларда, төрле конкурс, ярышларда алдынгы булып бардык. Киләчәктә алган белемебез безгә хезмәт итәр дип өметләнәм. Рәхмәт Сезгә укытучылар.

**Сәйдәш Газизов, 9 нчы сыйныф укучысы**

**Без - сәләтлеләр**

Барлык кешедә аерым сәләт була диләр, ә без классыбыз белән сәләтлеләр...Без җырларга яратабыз. Башлангыч класстан башлап, 13 укучы без “Шатлык” ансамбленә

Мин 9 нчы сыйныфны тәмамлыйм. Бу еллар бик тиз үтеп китте! Мин дусларым белән мәктәпнең беренче көнендә очрашырга һәм каникуллар турындагы тәэсирләр белән уртаклашырга, шалтыратуны түземсезлек белән көткәнемне хәтерлим. Ә тагын, мин безнең беренче сыйныф сәгатен онытмаячакмын, без аны класс белән бергә җиңгән вакытта алдык. Спорттагы җиңүләребезне гел искә төшерәм. Без мөстәкыйль тормыш юлына басабыз һәм озак еллар дәвамында безне озатып йөрүчеләргә тирән рәхмәтебезне белдерәбез. Без сезнең өметләрегезне аклый алырбыз һәм киләчәктә зур үрләргә ирешербез дип өметләнәбез. Барлык укытучыларыбызга да теләкләрнең иң яхшыларын телибез.

**Хабибуллина Адиля, 9 нчы сыйныф укучысы**

Иң истәлекле вакыйгалар чыгарылыш сыйныфларда, ягъни 9 һәм 11 сыйныфларда була дип уйлыйм. Бу чыгарылышны, имтиханнарны көтү, һәм аларга әзерләнү. Соңгы тапкыр коридорда йөргәндә, үткән еллар хатирәләрен искә төшереп, сыйныфташлар һәм укытучылар белән хушлашу - иң аянычлысы. Минем хәтеремдә мәңге калыр мәктәм елларым.

**Ильвина Сибагатова, 9 нчы сыйныф укучысы**

Мәктәп минем өчен икенче йортым кебек. Мина белем учагын кабызучы, яңа үрләр, физкультура фәнен яратырга өйрәтүче, күп яңа әйберләрне күрсәтүче булып истә калыр. Мин укытучыларыма, сыйныфташларыма бик рәхмәтлемен!

**Зөлфәт Мөхәметшин, 9 нчы сыйныф укучысы**

Теге елны (2024 елны) ,без ,минем сыйныфым белән, Галиәсгар Камалның "Бәхетсез егет" дигән спектаклен сәхнәгә куйдык. Һәр көн саен без аны кабатладык, репетицияләрне клубта ясадык. Костюмнарны тектек, декорацияләрне узебез эшләдек. Спектаклебезне жюри әгъзаләренә курсәтеп дипломга лаек булдык, мактаулар һәм чәчәкләр алдык. Үзебезгә зур тормыш тәҗрибәсен алдык. Мәктәптәге һәр вакыйга, һәр мизгел минем күңелемдә сакланыр.

**Зөхрә Ганиева, 9 нчы сыйныф укучысы**

Яраткан мәктәптә минем
Куп кенә нәрсә булды:
Шулкадәр алдым белем,
Никадәр гомер узды.
Тугыз ел дәверендә
Тойдым төрле-төрле хисләр:
Буладырмы ул шатлык бишкә
Яки ачу икегә.
Ләкин менә шуны беләм:
Яратам мин бу мәктәпне,
Сөенеч тоеп ана керәм;
Кешеләре жылыта йөрәкне!

**Кәрим Хафизов 9 нчы сыйныф укучысы**

йөрибез. Житәкчебез Абдуллина Ләйлә Рөстәм кызы безне җыр сәнгатенә өйрәтә. Атна саен дәресләрне калдырмыйча, вокал серләренә төшенәбез. Без аңа бик рәхмәтле. Матур җырлар өйрәнеп инде зур сәхнәләрдә чыгыш ясадык. Ел саен “Созвездие - Йолдызлык” бәйгесендә катнашабыз. Быел да район этабында беренче урынны яуладык. Алдагы елларда Балтач, Әтнә районнары , Биектау шәһәре сәхнәләрендә , Сабантуй мәйданнарында чыгыш ясадык. “Чәчәк кебек чаклар”, “Дөнья матур”, “Караужа авылы көе”, “Бүген Җиңү бәйрәме”, “Такмак”, “Әйлән-бәйлән” исемле күп җырларны өйрәнеп башкардык, матур хәрәкәтләр дә эшләп, чыгышлар тулы композиция булып килеп чыга. Безнең чыгышларны әти - әниләр дә яратып карыйлар, алар концерт чыгышларыбызга киләләр. Матур концерт киемнәребез бик зәвыклы һәм уңайлы итеп тегелгән, аларны безнең үлчәмнәрне алып махсус безнең өчен тегәләр, без шулай чын артистлар кебек зур концертларда катнашабыз. Иң яраткан сәхнәбез - Әтнә театры сәхнәсе, без монда тәүге чыгышларыбызны ясадык, беренче уңышларга ирештек, беренче алкышларны кабул итеп алдык. Сәхнә үз үзеңә ышанычлы булырга өйрәтә, без җырларга бик яратабыз.

**Бариева Зилия 5класс укучысы**

**Сугыш...каһәр төшкән сугыш**.

Күпме ачы күз яшен,кайгы-хәсрәтләрне үз эченә алга куркыныч сүз! Кемнәрнең генә язмышына кагылмаган да кемнәрнең башларына кайгы, күз яше, хәсрәт китермәгә ул. Ничә миллион кешенең гомерен өзгән,
күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган. Зур шәһәрләр җимерелгән, җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан.

Хәзерге көннәрдә Бөек Ватан сугышы ветераннары бик әз калган. Ләкин алардан яшьрәк буынга сугыш тагын да зуррак тәэсир калдырган. Аларны сугыш чоры балалары – тыл ветераннары дип атыйлар. Минем дәү әбием Нурания дә алар рәтенә керә.

Безнең өстә киндер күлмәк, аякта чабата иде.
Бишмәтнең дә тышы киндердән була иде. Бала-чагаларның кайберлләре, өстенә кием булмау сәбәпле, мәктәпкә укырга йөри алмыйча, мич башында җылынып утыралар иде,- дип искә алды әбием.

Татарстан илнең көчле тыл базасына әверелә.Казан авиация, ясалма каучук заводлары, кинопленка, тегү фабрикалары, мех комбинаты фронт өчен эшли. Җиңү көнен якынайтуга үзләреннән зур өлеш кертә.

Сугыш чоры баласы буларак, бу авыр елларда үткән балачагы, аның күргәннәре турында үзе сөйләгән хатирәләрне язасым килә.

Сугыш башланганда дәү әбиемә 9 яшь кенә булган. Ул вакытларны, башыннан кичкән вакыйгаларны сорасаң, еш кына, тел белән генә әйтеп, аңлатып бетерә торган түгел, дип кабатлый иде. Ул безгә, сез бик бәхетле заман балалары дип әйтергә яратты.

Ул дәһшәтле елларда, әтиләре сугышка киткәч, гаиләдә әнисенә төп таяныч, ярдәмче булып кала әбием. **«Барысы да фронт өчен!», «Барысы да Җиңү өчен!» дигән өндәмәләр буенча яшәгән алар. Ир-атлар сугышка киткәч, берникадәр ятимләнеп калган авылларда җир эшкәртү, икмәк үстерү, ит-сөт җитештерү кебек эшләр нигездә хатын-кыз җилкәсенә төшә. 9-10 яшьлек балалар да, 60-70 яшьлек карт-коры да җиң сызганып колхоз эшенә керешә. Шулай итеп алар Бөек Җиңүне якынайтуга лаеклы өлеш кертәләр.**

Әнинең “Нәрсә ашатыйм инде бу балакайларыма“,- дип елап утырганнары әле дә күз алдымда тора. Яз көне черек бәрәңге, ә җәй житсә, кычыткан ашлары (аңа азрак сөт кушып) пешереп бирәләр иде. Иске эскерт урыннарыннан төрле чүп, алабута орлыгы алып кайтып тартып, аннан ипи пешерәләр иде. Өйгә ягарга утын да юк иде, аны җылытыр өчен салам яга идек. Әниләр басудан эштән кайткач, сугышка диеп, җылы аяк киемнәре әзерлиләр иде,- дип сөйләде әбием.

Ул ат җигеп, тырмага йөргән, бәрәңге басуыннан черек бәрәңге җыеп, тамакларын ялгаганнар. Язгы чәчү вакытында, картлар чәчү чәчкәндә, аларга юл күрсәтүче хезмәтен үтәгән. Урып-җыю вакытында калган башакларны җыеп, колхозга тапшырган. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр авыр хезмәт, кыскасы, барысын да татырга туры килә.

**Әйе, бу сугыш илебезгә күпме кайгы хәсрәт, күпме күз яше китереп, күпме сабыйларны ятим калдырды. Шулай булуга карамастан, Ватанга булган мәхәббәт, тыныч, бәхетле киләчәккә ышаныч барысыннан да көчле булып, Бөек Җиңүгә китерде.**

Дәү әбием быел вафат булды.Шулай да, әбием исән вакытта, аның белән сөйләшеп, истәлекләр яза алуыма мин бик бәхетле.



Галәвиев Ранил, 2 нче сыйныф укучысы




